СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2026 г. Агрыз № 15-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче аерым муниципаль берәмлекләрнең чикләре турында

"Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Әгерҗе шәһәре», «Көчек авыл җирлеге», «Иске Эсләк авыл җирлеге», «Бима авыл җирлеге», «Красный Бор авыл җирлеге», «Салагыш авыл җирлеге», «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен Удмурт Республикасы чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү инициативасы белән чыгарга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләрнең чикләрен туры китерү турында фикер белдерергә тәкъдим итергә.

3. Бу карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов